ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» 2005 елның 30 декабрендәге 138-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш), № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 1 өлештә «һәм ремонт ясауга» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 2 өлештә:
беренче абзацта «һәм ремонтлауга» сүзләрен төшереп калдырырга;
икенче абзацта «каты көнкүреш калдыкларын алып китү» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар белән эш итү» сүзләренә алмаштырырга;
өченче абзацта «һәм ремонтлау» сүзләрен төшереп калдырырга, «каты көнкүреш калдыкларын алып китү» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар белән эш итү» сүзләренә алмаштырырга;
дүртенче абзацта «һәм ремонтлау» сүзләрен төшереп калдырырга, «каты көнкүреш калдыкларын алып китү» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар белән эш итү» сүзләренә алмаштырырга;
бишенче абзацта «һәм ремонтлау» сүзләрен төшереп калдырырга, «каты көнкүреш калдыкларын алып китү» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар белән эш итү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 нче кушымтада «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 17-ТРЗ